**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 октябрь № 787

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системаларын кертү турында» 2008 ел, 18 август, 592 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системаларын билгеләү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системаларын кертү турында» 2008 ел, 18 август, 592 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 5 декабрь, 869 нчы; 2009 ел, 2 февраль, 59 нчы; 2010 ел, 1 март, 102 нче; 2010 ел, 14 июль, 564 нче; 2010 ел, 24 август, 675 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1171 нче; 2011 ел, 6 сентябрь, 746 нчы; 2011 ел, 30 ноябрь, 978 нче; 2012 ел, 21 июнь, 537 нче; 2012 ел, 27 ноябрь, 1026 нчы; 2013 ел, 6 февраль, 76 нчы; 2013 ел, 19 февраль, 113 нче; 2013 ел, 2 апрель, 222 нче; 2014 ел, 16 июль, 502 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системаларын билгеләү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

беренче абзацта «учреждениеләр» сүзеннән соң «һәм оешмалар» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацка «яки һөнәр стандартлар» сүзләрен өстәргә;

бишенче һәм алтынчы абзацларга «һәм оешмаларда» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Учреждениеләр һәм оешмалар хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү системасы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына гамәлгә ашыру өчен бирелгән халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәләр нигезендә билгеләнә, алар Татарстан Республикасы  алып баруындагы предметлар һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы бергәләп алып баруындагы предметлар буенча вәкаләтләрне тормышка ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм оешмаларының гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан раслана.»;

3 пунктта «учреждениеләр» сүзләреннән соң «һәм оешмалар» сүзләрен өстәргә;

5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Стимуллаштыручы характердагы түләүләр зурлыклары һәм аларны гамәлгә ашыру шартлары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына гамәлгә ашыру өчен бирелгән халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәләр нигезендә күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә, алар Татарстан Республикасы  алып баруындагы предметлар һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы бергәләп алып баруындагы предметлар буенча вәкаләтләрне тормышка ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм оешмаларының гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан раслана.»;

6 пунктның беренче – өченче абзацларында тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «учреждение» сүзеннән соң тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «һәм оешма» сүзләрен өстәргә;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Учреждение һәм оешманың төп персоналына аларны тормышка ашыру өчен учреждение һәм оешма төзелгән төп функцияләрне үтәүне турыдан-туры тәэмин итүче хезмәткәрләр карый.

Төп персоналга караган икътисадый эшчәнлек төрләре буенча учреждение һәм оешмалар хезмәткәрләре вазыйфалары һәм профессияләре исемлекләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештереп, тиешле тармак министрлыклары билгели.»;

8 пунктта:

беренче – өченче абзацларында тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «учреждение» сүзеннән соң тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «һәм оешма» сүзләрен өстәргә;

дүртенче, бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Учреждениеләр һәм оешмаларның җитәкчеләре, җитәкче урынбасарлары, баш хисапчыларының финанслар белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары исәбеннән формалаша һәм календарь ел өчен исәпләнә торган уртача айлык эш хакының һәм учреждениеләр һәм оешмалар хезмәткәрләре уртача айлык эш хакының (тиешле җитәкче, аның урынбасарлары, баш хисапчы эш хакын исәпкә алмыйча) чагыштырмасының күрсәтелгән чик дәрәҗәсе тиешле учреждениеләр һәм оешмаларның гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан 1 дән 8 гә кадәр кабатлылыкта билгеләнә.

Әлеге 1 дән 8 гә кадәр кабатлылыктагы учреждение һәм оешма җитәкчесе, җитәкче урынбасарлары, баш хисапчысының уртача айлык эш хакы һәм учреждение һәм оешма хезмәткәрләре уртача айлык эш хакы чагыштырмасының күрсәтелгән чик дәрәҗәсе финанслар белән тәэмин итүнең барлык чыганакларын исәпкә алып, тиешле финанс елына учреждение һәм оешманың расланган хезмәткә түләү фонды кысаларында билгеләнә.»;

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

9 пунктта «дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм мәгариф оешмалары» сүзләрен «учреждениеләр һәм оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның беренче, икенче абзацларында тиешле килешләрдәге «учреждение» сүзеннән соң тиешле килешләрдәге «һәм оешма» сүзләрен өстәргә;

11 пунктның беренче, икенче абзацларында тиешле саннардагы «учреждение» сүзеннән соң тиешле саннардагы «һәм оешма» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков